| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.12.2016 Казан ш. № 3-14/э

2017 елга Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә аерым тарифлар билгеләү хакында

2003 елның 26 мартындагы «Электр энергетикасы турында» 35-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 29 декабрендәге «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең 2004 елның 6 августындагы «Ваклап сату (кулланучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 20-э/2 номерлы һәм 2012 елның 17 февралендәге «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә шушы карарның 1 кушымтасы буенча календарь чорларына бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергәннән башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булачак.

3. 2017 елга территориаль челтәр оешмаларының зарури тулай табышын (югалтуларны түләүне исәпкә алмыйча) әлеге карарның 2 кушымтасына туры китереп билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының
23.12.2016 № 3-14/э карарына
1 кушымта

## Татарстан Республикасы территориясендә челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә 2017 елның 1 гыйнварыннан башлап 2017 елның 31 декабренә кадәр календарь чорларына бүленгән аерым тарифлар

| № п/п | Челтәр оешмаларының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | | электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | технологик сарыф (югалтулар) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2017 | 1 359 452,65 | 125,13 | 2,04546 | 1 359 452,65 | 133,88 | 2,05422 |
| 2 | «Смежная сетевая компания «Интеграция» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2017 | 306 078,93 | 47,39 | 0,64890 | 306 078,93 | 50,71 | 0,65222 |
| 3 | «Энерго-Система» җаваплылыгы | 2017 | 72 116,50 | 129,85 | 0,36546 | 72 116,50 | 138,94 | 0,37455 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | чикләнгән җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
23.12.2016 № 3-14/э карарына
2 кушымта

2017 елга территориаль челтәр оешмаларының зарури тулай табышы
(югалтуларга түләүләрне исәпкә алмыйча)

| № п/п | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Челтәр оешмаларының югалтуларны исәпкә алмаган ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1 | «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2017 | 8 558,94 |
| 2 | «Смежная сетевая компания «Интеграция» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2017 | 38 209,67 |
| 3 | «Энерго-Система» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2017 | 10 178,38 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге